| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

«21» марта 2019 с. Тюлячи № 157

Теләче муниципаль районы милке турындагы мәгълүматны ачу турында Нигезләмәне раслау турында

Татарстан Республикасы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре министрлыгының 2019 елның 25 гыйнварындагы 1-31/909 санлы хатын караганнан соң һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 327 санлы «Татарстан Республикасы милке турындагы мәгълүматны ачу турында Нигезләмәне раслау турында»гы карарына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Теләче муниципаль районы милке турындагы мәгълүматны ачу турында Нигезләмәне Кушымтага туры китереп расларга.
2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.
3. Карарның үтәлешенә контрольне Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Н.М. Сөнгатуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның «21» 03
157 санлы Карарына
Кушымта

**Теләче муниципаль районы милке турындагы мәгълүматны ачу турында НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Теләче муниципаль районы милке турындагы мәгълүматны ачу турында Нигезләмә 2006 елның 27 июлендәге 149 санлы «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре, мәгълүматны саклау турында»гы, 2001 елның 21 декабрендәге 178 санлы «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы, 1993 елның 21 июлендәге 5485-1 санлы «Дәүләт сере турында»гы Федераль законнарга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 327 санлы «Татарстан Республикасы милке турындагы мәгълүматны ачу турында Нигезләмәне раслау турында»гы карарына нигезләнеп эшләнде һәм Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан ачылучы Теләче муниципаль районы муниципаль милке турындагы мәгълүмат составын, шулай ук аны ачуның ысулларын, тәртибен һәм срокларын, шул исәптән милекнең аерым объектлары буенча да, билгели.

1.2. Теләче муниципаль районы муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу – кызыксынган затларга аннан файдалануны рөхсәт итүне тәэмин итүне аңлата.

1.3. Теләче муниципаль районы муниципаль милкенең исәпкә алынган объектлары турындагы мәгълүмат Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары һәм муниципаль норматив-хокукый актларга туры китереп бирелә. Сорала торган мәгълүматта дәүләт сере булган очракта, мәгълүмат бирүдән баш тартумөмкин.

1.4. Юридик затлар буенча бирелә торган мәгълүмат аларның мәнфәгатьләренә каршы кулланылган очракта, Россия Федерациясе законнары белән җаваплылыкка тарту каралган.

1.5. Теләче муниципаль районының муниципаль милке турында мәгълүмат Теләче муниципаль районының муниципаль милке Реестрында теркәлгән мәгълүматлар, Теләче муниципаль районының муниципаль милкендәге Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының мәгълүмат базасында булган җир участоклары турындагы мәгълүматлар күләмендә бирелә.

1.6. Теләче муниципаль районының муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу мәгълүматны тарату һәм кызыксынган затларга бирү формасында башкарыла.

Мәгълүматны тарату массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару һәм Интернет челтәре сайтында урнаштыру юлы белән башкарыла.

Мәгълүмат кызыксынган затларның язмача мөрәҗәгатеннән соң, шулай ук милекнең аерым объектлары буенча да, бирелә.

## 2. Мәгълүматны тарату

2.1. Интернет челтәре сайты аша таратылучы Теләче муниципаль районының муниципаль милке турындагы мәгълүмат түбәндәге исемлекне күздә тота (мәгълүматтан файдалану законнар белән чикләнгән очрактан тыш):

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль учреждениеләре исемлеге (исеме, урнашкан урыны);
- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләр исемлеге (исеме, урнашкан урыны);
- Устав капиталы өлеше (акцияләр пакеты) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләре исемлеге (исеме, хуҗалык җәмгыятенең урнашкан урыны, устав капиталында район өлеше);
- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы милкендә булган күчемсез милек (биналар, йортлар) исемлеге (исеме, урнашкан урыны, мәйданы, нинди максатта файдалануга бирелгән, файдалануны чикләү, өченче затларның хокуклары);
- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның прогноз планы (программасы);
- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыру прогноз планының (программасының) үтәлеше турында хисап;
- Теләче муниципаль районы муниципаль милке турындагы мәгълүмат шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында да бастырылырга мөмкин.

2.2. Әлеге Нигезләмәнең 2.1. Пунктында күрсәтелгән 1 гыйнварга булган мәгълүматлар Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының http://tulachi.tatarstan.ru/ рәсми сайтында ел саен, финанс елы тәмамланганнан соңдүрт айдан да соңга калмыйча, бастырылырга тиеш.

2.3. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль милке булган объектлар турындагы мәгълүмат, аларны хосусыйлаштыру белән бәйле рәвештә, хосусыйлаштыру турындагы законнар белән билгеләнгән күләмдә ачылырга тиеш.

## 3. Кызыксынган затларга мәгълүмат бирү

3.1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль милке Реестрында теркәлгән аерым милек объектлары буенча (алга таба -

исәпкә алу объектлары) мәгълүмат кызыксынган затларның мөрәҗәгате буенча хат яки Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль милке Реестрыннан өземтә формасында бирелә.

3.2. Исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат (яки аны бирмәү турында дәлилләнгән карар) Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан мөрәҗәгать теркәлгән көннән 30 көннән дә соңга калмыйча бирелә.

3.3. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль милке Реестрыннан өземтә бирелә:

- исәпкә алу объектларының хокуклы биләүчеләренә яки аларның законлы вәкилләренә;

- исәпкә алу объектларының хокуклы биләүчеләреннән яки аларның законлы вәкилләреннән ышаныч язуы алган физик һәм юридик затларга;

- Россия Федерациясе Хисап палатасына, Татарстан Республикасы Хисап палатасына, Теләче районының контроль-хисап палатасына;

- җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт хакимияте органнарына;

- дәүләт хакимиятенең федераль органнарына, шул исәптән:

а) күчемсез милеккә хокукны дәүләт теркәве һәм килешүләр уздыручы органнарга;

б) салым органнарына;

в) исәпкә алу объектлары һәм (яки) аларның хокуклы биләүчеләре белән бәйле эшләр алып баручы судларга, хокук саклау органнарына, суд приставлары-башкаручыларга;

г) монополиягә каршы федераль органга һәм аның Татарстан Республикасындагы территориаль органына.

3.4. Нигезләмәнең 3.3 пунктында күрсәтелмәгән кызыксынган затларга исәпкә алу объектларының Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципальмилке Реестрында булулары турындагы мәгълүмат кына бирелә.

3.5. Сораган мәгълүматны бирүдән язмача баш тарту дәлилләнгән булырга тиеш.

Сораган мәгълүматны бирүдән баш тарту өчен түбәндәге сәбәпләрнигез булып тора:

- сораган мәгълүматны файдалану законнар белән чикләнгән очракта;

- мөрәҗәгатьнең эчтәлеге белән әлеге зат мәгълүмат сораган объектны тәңгәлләштерү мөмкин булмаганда;

- мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән объект буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль милке Реестрында булмаганда.